**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**КУЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422612, РТ, Лаишевский район,
п. Мысовский, ул.Центральная, д.33 а
тел:89061111775, kuuk.la@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КӨЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
422612, РТ, Лаеш район, Мысовский
поселок, Центральная ур, 33 а йорт
тел: 89061111775, kuuk.la@tatar.ru

---

**2024 елның 07 марты** **9 номер**

# КАРАР

## «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Көек авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022елның 8 декабрендәге 58 номерлы Көек авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (23.08.2023ел, 23.11.2023 ел карарларындагы үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Көек авыл җирлеге советы карар кабул итте**:**

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау турында»2022 елның 8 декабрендәге 58 номерлы Көек авыл җирлеге карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә;

1) **7 статьяның 6 өлеше** түбәндәге эчтәлектәге пунктча белән тулыландырырга:

Бюджет акчаларының баш идарәчесе:

"Электрон бюджет" иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында, капитал салуларын финанс белән тәэмин итү (финанслаштыру) чыганагы федераль бюджет акчалары булган, капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез милек объектлары турында белешмәләр формалаштыра;

2) **27 статьяның 7 өлешендәге 5 абзацтагы сүзләр**

"Федераль адреслы инвестиция программасында каралган" төшереп калдырырга, "Федераль адреслы инвестиция программасына кертелгән чараларны (зурайтылган инвестиция проектларын) детальләштерүгә бәйле рәвештә"сүзләрен " капиталь

төзелеш объектлары, күчемсез мөлкәт объектлары реестрына кертелгән белешмәләрне детальләштерүгә бәйле рәвештә" сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Көек җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Көек**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Л.М.Сатдинова**